

Ел саен Халыкара Аналар коне унаеннан республикабыз Главасы Владимир Волков Мордовия Республикасы Йортында кvпбалалы аналар хормәтенә очрашу оештыра. Быел да, 29нчы ноябрь конне, чара тантаналы рәвештә vтте.
Аналар адресына әйтелгән ин матур сvзләр дә һәр кеше жәмгыять һәм дәvләт тормышында анын роле турында әйтеп бетерә алмаслык. Ана булу бер дәвердә дә жинел булмаган. Әмма бернәрсәгә дә карамыйча, сугыш эчендә, табигать катаклизмнары шартларында, хан сарайларында яки алачыкта яшәсә дә, хатын-кыз vзенен топ миссиясен vти - бала vстерә, тәрбияли, буыннар чылбырын дәвам итә. Баланы киләчәктә жәмгыятькә файда китерердәй кеше итеп vстерv- һәр ананын изге бурычы. Шулай булганда гына ул vзен чын мәгънәсендә бәхетле хис итә.      «Нык гаилә - нык дәvләт» дип юкка гына әйтмәгәннәр. Мордовия Главасы Владимир Волков тантаналы рәвештә, урнашкан традиция  буенча, чакырылган кvпбалалы аналарны котлап РМ Главасы Почетлы дипломы, «За заслуги в воспитании детей» дипломы һәм акчалата премияләр белән бvләкләде.
- Это одна из наиболее волнительных встреч года, - ди чыгышында Мордовия Главасы, чакырылган әниләргә тобәп. - В семье формируются нравственные устои, формируются духовные ценности, закладывается его гражданская позиция. Семья всегда была и остается главной ценностью государства.
Владимир Волков тагы республикабызда кvпбалалы гаиләләрне яклаучы, аларнын авторитетын кvтәрv, гаилә әһәмиятен vстерv чаралары һәм Программаларынын тормышка ашырылуы; әхлаки һәм матди булышлык турында сойләде. Мәсәлән, республикабызда оченче, дvртенче һәм чиратта  туасы балаларга Аналар капиталы бирелә, ди. Шулай, аларга быел 150 мен сум - оченче, 180 мен сум - дvртенче һәм тагы туасы балага сертификат тапшырылган. Бу акчаларны яшәv шартларын яхшыртырга-квартира сатып алырга, баланын белеменә, ананын киләчәк пенсиясенә тотарга була. Мордовия Главасы исеменнән кvпбалалы гаиләләрдәге 90 мен бала га Яна ел бәйрәмнәренә бvләк тапшырылыр.

